| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Альметьевского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Әлмәт авыл җирлеге советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2017 ел, 29 декабрь № 27

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы президиумының 2016 елның 13 октябрендәге «муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында» гы ПР-26-4 номерлы карарын игътибарга алып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставына таянып, норматив хокукый базаны камилләштерү, авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатыннан Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару өчен Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын (сәркәтибен) билгеләргә.

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән җирле үзидарә органнарына һәм аларның вәкаләтле затларына әлеге карарның 1 пункты белән расланган акт нигезендә:

1) 2018 елның 1 сентябренә кадәр муниципаль норматив хокукый актлар реестрын формалаштырырга һәм аларны җирлек бүлегендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.;

2) муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруны һәм аларны җирлек бүлегендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында актуаль хәлдә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе — Д.Ә. Газизов.